ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә:

а) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ – $3^3$ пунктлар өстәргә:

«$3^1$) Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтүче (үткән) гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән хәрби формированиеләрдә һәм органнарда хәрби хезмәттә (хезмәттә) булучы (булган) гражданнар, аларның Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашуы һәм (яисә) Россия Федерациясе территориясенә кораллы басып керүгә каршы тору, Россия Федерациясе Дәүләт чигендә һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрү районнарына чиктәш Россия Федерациясе субъектларының чик буе территорияләрендә хәрби провокация барышында бурычларны үтәве шарты белән, күрсәтелгән территорияләрдә булучы (булган) Россия Федерациясе хокук саклау органнары хезмәткәрләре (эшләүчеләре), күрсәтелгән территорияләрдә хезмәт функцияләре һәм башка шундый ук

функцияләр башкаручы (башкарган) гражданнар, шулай ук әлеге гражданнарның гаилә әгъзалары;

$3^2$) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ихтыярый ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән гражданнар, аларның Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашуы һәм (яисә) Россия Федерациясе территориясенә кораллы басып керүгә каршы тору, Россия Федерациясе Дәүләт чигендә һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрү районнарына чиктәш Россия Федерациясе субъектларының чик буе территорияләрендә хәрби провокация барышында бурычларны үтәве шарты белән, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ярдәм күрсәтүче оешма белән контракт төзегән (башка хокук мөнәсәбәтләре булган) гражданнар, аларның күрсәтелгән территорияләрдә махсус хәрби операциядә катнашуы шарты белән, шулай ук әлеге гражданнарның гаилә әгъзалары;

$3^3$) Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы дәүләт хакимияте органнары карарлары нигезендә 2014 елның 11 маеннан башлап Донецк Халык Республикасы Кораллы Көчләре, Луганск Халык Республикасы Халык милициясе, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы хәрби формированиеләре һәм органнары составында хәрби гамәлләрдә катнашкан затлар, шулай ук әлеге затларның гаилә әгъзалары;»;

б) $8^3$ – $8^5$ пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 2 өлештә:

а) $10^2$ пунктта «ятим балаларның» сүзләрен «инвалид балаларның, ятим балаларның» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 17 – 21 пунктлар өстәргә:

«17) хәрби хезмәткәрләрне акчалата тәэмин итү һәм «Хәрби хезмәткәрләрнең акчалата тәэминаты һәм аларга аерым түләүләр бирү турында» 2011 елның 7 ноябрендәге 306-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә аларга аерым түләүләр бирүне тәэмин итү;

18) әлеге статьяның 1 өлешендәге $3^1$ һәм $3^2$ пунктларында күрсәтелгән затларга ташламалар, социаль гарантияләр һәм компенсацияләр бирү;

19) әлеге статьяның 1 өлешендәге $3^3$ пунктында күрсәтелгән затларга ташламалар, социаль гарантияләр һәм компенсацияләр бирү;

20) әлеге статьяның 1 өлешендәге $3^1$ һәм $3^2$ пунктларында күрсәтелгән затлар (аларның гаилә әгъзаларыннан тыш) арасыннан булган гражданны хәбәрсез югалган дип тану;

21) әлеге статьяның 1 өлешендәге $3^1$ һәм $3^2$ пунктларында күрсәтелгән затлар (аларның гаилә әгъзаларыннан тыш) арасыннан булган гражданны үлгән дип игълан итү.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 өлешенең $3^1$ һәм $3^2$ пунктлары, 2 өлешенең 17, 18, 20 һәм 21 пунктлары нигезләмәләренең гамәлдә көче 2022 елның 24 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 68-ТРЗ